БАЛЫКЧЫЛАР СЫНАВЫ
Кәрәкә – керосинга, карп борчакка алдана
> 3

105 ЕЛЛЫК ТАРИХ
Галимҗан Нигъмәти баш мөхәррир булган чорда газетаның хәле
> 3

ИФИРА САЙБАТАЛОВА:
«Йокыдан иртәнге биштә уянам, гантельләр күтәрәм»
> 4

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ
«Хайван» сүзенең чын мәгънәсен шул чордарак төшендем»
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 3 (28970) | Чәршәмбе | 11 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ГАЗ КИЛӘ, КАПКАДАН КЕРТЕГЕЗ!

Яшәеш

Республикада торак йортларга кадәр бушлай газ тоташтыру программасы (догазификация) дәвам итә. Исегезгә төшерәбез: Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча әлеге программа кысасында газны йортка кадәр китерәләр, аны өй эченә кертүне һәркем үзе хәл итә. Татарстанда бу эшнең барышы турында «Газпром трансгаз Казань» оешмасының генераль директоры Рөстәм Усманов Министрлар Кабинетында узган брифингта сөйләде.

Бүген Татарстан халкыннан, әлеге программа буенча газ кертүне сорап, 17 мең гариза килгән. 16 мең кеше белән килешү төзелгән. 12 мең хуҗалыкка кадәр газны китергәннәр, ә 6 мең гаилә исә аны тоташтырган да инде.

– Республикада газ кулланучылар елдан-ел арта. Яңа бистәләр төзелә, сәнәгать оешмалары ачыла. Яңа программа ярдәмендә без халыкның тормышын җиңеләйтәчәкбез, – ди Рөстәм Усманов. – Моның өчен дәүләттән 1 млрд 12 миллион сум өстәмә акча бирелде. Без бу акчага яңа газ үткәргечләр төзибез. Яңа станцияләр сафка баса. Зәңгәр ягулыкны капка төбенә кадәр алып килеп тоташтыру өчен шактый эш башкарырга кирәк. Кайбер бистәләргә бөтенләй газ да кермәгән була.

Йортларга бушлай газ кертү мөмкинлеге булганда, җитәкче аны тоташтырып калырга куша. Әгәр сез яшәгән җирдә газ кергән икән, аны үз йортыгызга кадәр китерүне сорап, гариза яза аласыз. Йорт хуҗасы икәнлегегезне раслаучы документ, газны җылыныр һәм ризык пешерер өчен тоташтыруыгыз турында белешмә кирәк. Быелдан бу программага республиканың мәгариф һәм сәламәтлек саклау оешмалары да кушылачак. Ул капка төбенә кадәр киләчәк, бинага кадәр кертүне йә район хакимияте, йә инде оешма үзе хәл итәчәк.

Шушы көннәрдә редакциягә Спас районының Иске Рәҗәп авылыннан Әнвәр абый Фәсәхов мөрәҗәгать иткән иде. Ул да өенә газ кермәүдән зарлана. Баксаң, аның инде капка төбенә зәңгәр ягулык килгәненә байтак еллар икән. Тик менә тоташтыру гына соңга калган. Андый чакта нишләргә соң? Республика халкы газны өйгә кертү кыйммәт дип зарланса, кайберәүләр кемгә мөрәҗәгать итәсен дә белми икән әле. Әнвәр абый проблемасын хәл иттек без. Теләге булса, аңа газны хәзер үк тоташтырачаклар. Түләсен генә. Ә түләү арзан түгел. Әйтик, Казан читендәге бер бистә яки Тукай районындагы бер авылда яшәүче кешегә моның өчен кимендә 120 мең сум акча түләргә кирәк булачак. «Бу суммага газ казаны, исәпләгеч һәм башкарылган хезмәт өчен түләү керә», – ди Рөстәм Усманов.

Акчаңны түләгәч, алданасы да килми бит әле. Газ тоташтыручыларны ничек сайларга соң? Рөстәм Усманов бу сорауга да җавап бирде. Баксаң, «Газпром трансгаз Казань» оешмасы бу эшкә алынса, аларның хезмәте шактый кыйммәт килеп чыга икән. Шуңа күрә ул кече эшмәкәрләргә, шәхси оешмаларга мөрәҗәгать итәргә куша. Болай эшләгәндә, арзанракка төшәчәк. Озак еллар эшләү тәҗрибәсе булган оешмаларның исемлеге «Газпром трансгаз Казань» оешмасы сайтында да бирелгән икән.

Очрашуда шулай ук авыл клублары һәм ФАПларны газлаштыру турында да сүз булды. Татарстанның сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Марат Миңнебаев зәңгәр ягулык булмаган мәдәният йортлары турында үзләренә хәбәр итәргә кушты. Быелның 1 мартыннан исә нәкъ менә социаль әһәмиятле оешмаларны газлаштыру буенча дәүләт программасы эшли башлаячак. Шулай ук 1 марттан газ кертү өчен бирелә торган субсидия күләме дә артачак. Рөстәм Усманов аны 100 мең сумга җитәр дип ышандырды.

Исегезгә төшерәбез: йорт эченә газ керткәндә бирелә торган субсидияне кайбер төр категория кешеләр (Бөек Ватан сугышы ветераннары, күпбалалы гаиләләр, инвалид бала тәрбияләүчеләр, I группа инвалидлар, авыр хәлдә яшәүче мохтаҗ гаиләләр) алырга хокуклы.

Очрашуда сөрем газы белән агуланучылар хакында да сүз булды. Көннәрнең салкын торуы аркасында килеп чыккан күңелсезлекләр кабатланмасын өчен, Рөстәм Усманов халыктан елга бер өйләренә килгән газчыларны кертүләрен сорады.

– Гади генә кагыйдәләрне үтәмәү аркасында гомерләр өзелә. Катлаулы эш тә түгел ул. Җилләтү системасы эшләмәү, фатирда яки йортта һава алмашу булмау аркасында күңелсез хәлләр килеп чыга. Безнең хезмәткәрләрнең абонентларыбызга бармый калганнары юк. Аларны кертмәүчеләр бар. Әмма без ничек тә бу проблеманы хәл итәргә тырышабыз. Идарәче оешмалар аша хуҗаларын табабыз, – ди ул. – Салкыннар безнең оешманы да читләтеп үтмәде. Казанның Константиновка бистәсендә газ җиһазы суыкларга түзмичә, эштән чыкты. Әмма без аварияне тиз бетердек. Җылыга иялəшкәч, салкында бер минут та торасы килми. Шуңа күрә, йортларга газ килүне хәл итеп, аны өйләрегезгә кертергә ашыгыгыз.

«Татар-информ» / Владимир Васильев

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЙОРТКА ГАЗ КИТЕРҮ ӨЧЕН ГАРИЗА ТАПШЫРУ ТӘРТИБЕ

Аны Дәүләт хезмәтләре порталы аша, кәгазьдә тутырып, горгаз, райгаз оешмаларына тапшырырга да була. Гаризада паспорт, СНИЛС мәгълүматларын, телефон номерын күрсәтергә, йортка һәм җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларның күчермәсен кушымта итеп бирергә кирәк. Кертү вакытын газ оешмасы билгели. Шартлары уңай булган очракта, ул шактый тиз булырга мөмкин. Иң мөһиме – сез яшәгән җирдә газ кертү өчен мөмкинлекләр булу. Төгәлрәк мәгълүматны **8 800 201 04 04** телефоны аша белешергә мөмкин. Шулай «Газпром трансгаз Казань» оешмасына **288-26-14, 288-26-16, 288-23-11** телефон номерлары аша мөрәҗәгать итә аласыз.

Бәя бәйсез түгел

Россиядә инфляция кими, әмма илдә бәяләрне контрольдә тоту бүген аеруча мөһим. Президент Владимир Путин Монополиягә каршы федераль хезмәт башлыгы Максим Шаскольскийга шулай дип белдергән.

Шаскольский әйтүенчә, халык өчен иң кирәкле товарларның бәясе даими игътибар үзәгендә тотыла. Биредә сүз азык-төлек кенә түгел, дарулар, нефть продуктлары, төзелеш материаллары, кәрәзле элемтә хезмәтләре турында да бара. Федераль сәүдә челтәрләрендә мондый товарларның өстәмә хакы 22 процентттан 5,5 процентка калдырылган. 70 төбәк сәүдә челтәре дә моны хуплаган. Шул ук вакытта икмәк, сөт, шикәр, иң кирәкле яшелчә бәясе үсүгә юл куймау буенча зур эш башкарылган.

Чик сызыгы билгеле

Татарстанның Мари Иле белән чиге турында төгәл мәгълүматлар булдырылып, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына (ЕГРН) кертелгән. Чик асылда урманнар һәм басулар аша уза. Гомуми озынлыгы – 334 чакрым.

Республиканың Мари Иле белән чиге төньяк-көнбатыштан уза. Чик буенда Яшел Үзән, Биектау, Әтнә, Арча һәм Балтач районнары урнашкан. Ә инде Мари Иле ягыннан – Волжск шәһәре, Волжск, Морки һәм Мари-Төрек районнары.

Хәзерге вакытта Татарстанның күрше төбәкләр белән сигез чигеннән өчесе ЕГРНга кертелгән инде. Болар – Оренбург өлкәсе, Башкортстан һәм Мари Иле республикалары белән чикләр. Шулай ук Чувашия, Удмуртия республикалары, Самара һәм Ульяновск өлкәләре белән ызан сызу турында килешүләргә кул куелган. Киров өлкәсе белән дә әлеге юнәлештә эш алып барыла. Росреестр идарәсе башлыгы Азат Җәббаров сүзләренә караганда, быел Татарстанның барлык чикләре рәсми рәвештә билгеләнәчәк.

Кунаклы йорт – хөрмәтле йорт

Яңа ел бәйрәмнәре вакытында Татарстанда барлыгы 160 мең турист булып киткән. Бу – узган елдагыга караганда 13 процентка зуррак сан. Туризм буенча дәүләт комитеты мәгълүматларына караганда, сәяхәтчеләр Казан Кремлен (190 мең кеше, алдагы елдагыдан 18 процентка күбрәк), Свияжск утрау-шәһәрчеген (38 мең кеше, 17 процентка күбрәк), Болгар (9,5 мең кеше, 31 процентка күбрәк), Алабуганы (7,5 мең кеше, 10 процентка күбрәк) бигрәк тә үз иткән.

Озын ялларда Татарстан башкаласы Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан туристлар белән дүртәр чартер рейсын кабул иткән. 2 гыйнварда Саратовтан туристлар поезды килеп төшкән.

Яңа Кырлайда 5 мең турист (2022 елдагыга караганда 25 процентка күбрәк) Кыш бабай резиденциясе белән танышып киткән. 31 декабрьдән 8 гыйнварга кадәр кунакханәләр – 76 процентка, 3–7 гыйнвар көннәрендә 95 процентка тулган.

25 декабрь – 8 гыйнвар аралыгында Казан Кремлендә барлыгы 230 меңнән артыграк кеше булган. Каникул вакытында музей-тыюлык территориясендә экскурсияләр үткәрелгән. Алардан 27 мең кеше файдаланган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Китмәс чир

Соңгы тәүлектә Татарстанда 54 кеше коронавирус йоктырган. Кичә 39 сырхау хастаханәгә озатылган. Коронавируска каршы көрәш буенча төбәк оператив штабы хәбәренә караганда, пандемия башланганнан бирле чир ияртүнең 193847 очрагы теркәлгән. 26 декабрьдән бирле республикада коронавирустан үлем-китем булмаган. Гомумән алганда, инфекция Татарстанда яшәүче 2009 кешенең гомерен өзгән.

Россия буенча мәгълүматларга килсәк, узган тәүлектә 3032 кеше коронавирус йоктырган. 10 гыйнварда 1067 кеше хастаханәгә эләккән. Пандемия башланганнан бирле илдә барлыгы 21832768 кеше чирләгән. Бер тәүлек эчендә 47 кеше инфекциядән вафат булган. Пандемия башланганнан бирле 394168 сырхау җан биргән.

Икътисад

Акча ярышы

СУМГА ҮСӘР НИГЕЗ БАРМЫ?

Узган ел ил икътисады өчен иң авыр еллардан булса да, чикләүләргә карамастан, яңа көнкүрешкә яраклаша алды ул. 2023 елда сум курсы ныгырга тиеш. Һәрхәлдә, икътисад белгечләре шуны фаразлый һәм шуңа ышана. Быел доллар курсы 62–63 сум булыр дигән өмет тә сүрелми. Шулай итеп, ил валютасына нәрсәләр йогынты ясый соң?

Дәүләт Думасының Финанс базары буенча комитеты башлыгы Анатолий Аксаков әйтүенчә, Россия валютасына төрле юнәлештәге факторлар тәэсир итә. Алар үз чиратында сумның ныгуына да, йомшаруына да китерергә мөмкин.

Анатолий Аксаков әйтүенчә, Россия валютасы энергия чыганаклары бәясенә бик бәйле. Әйтик, соңгы арада нефть бәясенең төшүе сумның да көчсезләнүенә китергән иде. Хәзер нефть бәясе күтәрелә башлагач, сум да ныгыр, дип белдерә комитет башлыгы.

Анатолий Аксаков шуны да искәртә: ил Президенты Владимир Путин килешүләрдә бәяләрне чикләү механизмын кулланучы чит ил юридик һәм физик затларына нефть һәм нефть продуктларын китерүне тыя торган указга кул куйды. Бу тыю агымдагы елның 1 июленә кадәр дәвам итәчәк.

Сумга каршы эшли торган факторлар да юк түгел, билгеле. Анатолий Аксаков искәрткәнчә, ул күбрәк дөнья икътисадындагы үзгәрешләргә бәйле. Бу, нигездә, энергия чыганакларына ихтыяҗ кимү һәм бәя төшүгә китерә. Шул исәптән нефтькә дә тәэсир итә.

Сум көченә йогынты ясаучы тагын бер сәбәп – экспортер компанияләрнең салым түләү чоры якынлашуы. Комитет башлыгы аңлатканча, бу чорда зур экспортер компанияләр, сум сатып алу һәм салым түләү өчен, актив рәвештә доллар сата башлый.

Анатолий Аксаков фикеренчә, сумның долларга курсы ил икътисады өчен кулай күрсәткеч (сүз уңаеннан, хәзер 70,3 сум). «Ел башында, махсус хәрби операция башланганчы, бер доллар 70 сум тирәсе иде. Ул импортерларга да, экспортерларга да кулай булды», – дип аңлатты ул.

«Финам» аналитигы Андрей Маслов исә Үзәк банк инфляцияне авызлыклый алмаса, сумның көчсезләнүе дәвам итәчәк дип саный. «Шул ук вакытта, Украинадагы хәрби низаг дәвам иткәндә, евро да басым астында калачак. Доллар, үз чиратында, киресенчә, кризис һәм тотрыксызлык чорында, «саклаучы валюта» («защитная валюта») буларак ныгыр дип көтелә. Тулаем алганда, якындагы айларда евро – 75 сум, ә Америка валютасы – 70 сумга якынаер дип көтәргә була, әмма бу – 2023 елның II кварталына булган фараз», – дип уйлый аналитик.

Фикер

Игорь КОХ, КФУның Идарә, икътисад һәм финанслар институты профессоры:
– Быелга нидер фаразлау кыен. Глобаль вазгыять нинди булыр бит. Дөнья базарында вазгыять нинди буласын берәү дә алдан фаразлый алмый. Яңа тискәре вакыйгалар булмаса, икътисад акрынлап торгызылачак, яңа шартларга яраклашачак. Гыйнварда, гадәттәгечә, икътисад беразга гына туктап торачак та, аннан соң яңадан элеккеге режимына кайтачак.

Сүзгә-сүз

Николай ПАТРУШЕВ, Россия Федерациясе Куркынычсызлык советы секретаре:

Россиягә финанс бәйсезлеге, шулай ук технология өлкәсендә суверенитет кирәк. Ә «ломоносов»лар һәм «кулибин»нар үзебездә дә җитәрлек. Аларны бары тик вакытында күрә белергә генә кирәк.

(«Аргументы и факты» газетасыннан)

РОССИЯДӘ – КРЕДИТ АЛУ

Россиядә соңгы 15 елда кредит алырга куркучы халык саны ике мәртәбә арткан. Бу хакта Superjob хезмәте хәбәр итә.

КРЕДИТ УЛ – ...

61 процент >> бурыч упкыны

13 процент >> ихтыяҗ булган нәрсәне бүген үк алу өчен мөмкинлек

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ГЛОБАЛЬ ФИНАНС ТҮНТӘРЕЛЕШЕ – ЯКЫНДА

Бразилиядә фетнә ничек тиз башланып китсә, шундый ук тизлектә бастырылды да. Дөнья дәүләтләре лидерлары (шул исәптән Кремль дә) яңа сайланган гамәлдәге Президент Лула да Силваны яклауларын белдерделәр. Америкада хәтта элекке Президент Болсонаруны илдән куу тәкъдиме белән чыккан сәясәтчеләр дә булды. Хәзер ул АКШтагы хастаханәләрнең берсендә эче авыртып ята. Шунысы кызык: Болсонару уң карашлы Президент иде, ул – глобаль капитализм тарафдары, ирекле базар яклы, шуңа карамастан, аның гыйсъянчылар штыгына утырып хакимлеккә кире кайту омтылышын беркем дә хупламады. Социализм тарафдары булган сул карашлы Силва исә теләктәшлек кенә түгел, хәрби ярдәмгә дә өметләнә ала. Чили Президенты хәтта аңа спецназ гаскәрләрен җибәрергә вәгъдә бирде.

Процент капиталына нигезләнгән финанс базарлары исә шок кичерүен дәвам иттерә. Планетакүләм зур банкларның финанслары романслар җырлый, ягъни эшләре шәп түгел. Элекке элемтәләр өзелә. Бик мулдан яудырылган Көнбатыш санкцияләре дә моңа булыша. Дәүләтләр яңа сукмаклар салып, үзара хезмәттәшлекнең таррак сукмакларында берләшергә мәҗбүрләр. Үзбәкстан, Азәрбайҗан, Казахстан автозаводларын берләштереп, «Автосәнәгатьнең төрки конгломераты»н төзиләр. Белгечләр андый берләшү Россия файдасына булыр дип өметләнә, чөнки Көнбатыш һәм япон автомобильләре безнең базарны ташлап китәләр. Кытай, Иран, Урта Азия машиналарының Россиядә үзара көндәшлеге башланыр, мөгаен.

Глобаль базарның вак кисәкләргә бүленүе – зур кризис нәтиҗәсе. Дөнья масштабында әле җитештерүнең түбәнәюе башланып кына килә дип саналса да, базарның төп атрибуты булган акча мәсьәләсе катлаулы. Зыянга эшләгән глобаль банкларның артуы зур финанс тетрәвенең якында гына булуына ишарә итә. Америка банкы Goldman Sachs берьюлы 3400 хезмәткәрен кыскартырга җыена. Бу – банк тарихындагы иң масштаблы кыскарту. Аңлашыла инде: эшләр хөрти булмаса, хезмәткәрләр белән бәхилләшмиләр.

Швейцария Хөкүмәте Швейцариянең милли банкыннан 2022 ел өчен түләүләр ала алмый (сүз дивидендлар турында бара), чөнки илнең Үзәк банкы үзенең 116 еллык тарихында иң зур зыянга эшләве турында игълан итте. Банк югалтулары 132 миллиард франк (143 миллиард доллар) булыр дип көтә. Бу элекке зыяннан 5 тапкыр күбрәк. Югалтуларның иң күп өлеше – 131 миллиард франк – чит ил валюталарындагы активларының бәясе төшү аркасында. Аларны Швейцария банкы франкның курсын түбәнәйтү максатыннан сатып алган. Дөньядагы иң ышанычлы булып саналган банк үз тарихында күрелмәгән зур югалтулар кичерә икән, алдагы көннәрнең түнтәрелеше ничек куәтле булачагын чамаларга мөмкин.

Россиядә

«ЗӘҢГӘР АГЫМ» ТИРӘСЕНДӘ БИЛ АЛЫШУ

Глобаль финанс базарларыннан кендеге өзелсә дә, Россиядә кризисның бер үк төрле билгеләре күзәтелә, чөнки нигез бер үк, ул – процент капиталы. Җитмәсә, Россияне санкцияләр дә талкый. Мәскәүдә бу хакта бик кычкырырга яратмасалар да, Bloomberg агентлыгы белдергәнчә, Urals маркалы нефть барреле бүген 37,8 доллардан сатыла. Бу дөнья бәясеннән ике тапкырдан да кимрәк, «Зур җиделек» илләре керткән 60 долларлык «түшәм»нән дә күпкә түбән. Транспортлау һәм иминиятләштерү чыгымнарын кушсаң, бәя үзкыйммәттән дә түбән чыга. Алда Россиянең нефть продуктларына эмбарго көтелә. Бу хакта без махсус язма әзерлибез. Кувейт Россия урынына Европага дизель ягулыгы сатарга әзерләнә. Берләшкән Гарәп Әмирлекләре һәм Согуд Гарәбстаны да нәкъ шул юнәлештә Көнбатыш базарын яуларга телиләр.

Россия Финанс министрлыгы, нефтьнең баррелен 50 доллардан сатканда, чыгаруны тәүлеккә 10 миллион баррель итеп саклап булса, нефть-газ керемнәре көтелгәннән 2,1 триллион сумга кимрәк булыр, дип исәпләп куйган. Югарыдагы саннарга карасак, югалтуларның гигант масштабы күз алдына килә. Нефтькә бәя күтәрелер дигән өмет кенә күңелне җылыта ала. Ул өмет кысыр булырга мөмкин, чөнки глобаль рецессия чимал бәяләрен күтәрми, төшерә.

Икенчел торак базарында бәяләрнең 25 процентка төшәчәге турында ярым рәсми хәбәрләр бар. Бәя төшү төзелеш темпларының кимүенә, кредитлауның түбәнәюенә китерәчәк. Банкларның хәле дә алкышларлык ук түгел. Белгечләр, Россия банклары 2023 елда массакүләм кыскартуларга әзерләнә, диләр. Вазгыять барлык финанс оешмаларында да шулай катлаулы икән. Кечерәк төбәк банклары аны аеруча авыр кичерәчәк.

Килеп туган хәл кичекмәстән тышкы базарларга товар сатуны арттыруны таләп итә. Әмма Россиянең төп товары – нефть һәм газ гына. Беренчесенең хәле санкцияләр нәтиҗәсендә авыр, икенчесе – газ тармагы – санкцияләр астында түгел, әмма зәңгәр ягулык экспортлау төрле сәбәпләр аркасында бик нык кимеде. Көнбатыш базарына газ белән үтеп керүнең бер генә юлы кала. Ул – Төркия. Әнкара бу мәсьәләдә Мәскәүгә кочак җәеп торган кебек күренсә дә, чынлыкта, үзе өчен файдалы булган зур ташламалар таләп итә, катгый таләпләр куя. Таләпләр арасында сәясиләре дә бар. Әрдоган командасының позициясе бик көчле. Бердән, ул Урта Азия дәүләтләре белән дә газ китертү турында зур килешүләр төзеде. Икенчедән, төрекләр Кара диңгездәге газ ятмаларын үзләштерә башладылар. Тулы куәткә газ чыгара башлагач, газ импортын 30 процентка киметергә җыенуларын белдерәләр. Алар бүген үк Евросоюз илләренә газ озата. Моңарчы Россиягә бәйле булган Болгария дә төрек газын ала башлый. Бер уенда уен тузы бирәү генә була, төрекләр кулында ул хәзер берничә. «Россия белән сөйләшүләр берничә юнәлештә дәвам итә. Без сөйләшүләрне безгә файдалы юнәлештә алып барабыз», – ди илнең энергетика һәм табигый ресурслар министры Фатих Донмез. Россия чарасыз хәлдә диярлек, шулай булгач, килешү төзелсә, максималь рәвештә төрекләр файдасына булачак, моңа шик юк.

МИЛЛӘТ ҺӘМ ТЕЛ СЫНАЛГАН ЧАК

Җанисәп

4 миллион 710 мең кеше. Соңгы җанисәп нәтиҗәләренә караганда, илдә әнә шул кадәр татар яши. Без – Россиядә халык саны буенча әле дә икенче урында. Татарстан тагын да ишәйгән. Тик соңгы тапкыр 2010 елда үткәрелгән җанисәп нәтиҗәләре белән чагыштырганда, илдә татарлар 600 меңгә диярлек кимегән. Саннар шулай ди.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Халык, мәш килеп, Яңа елны каршы алырга әзерләнеп йөргән 31 декабрьдә Росстат федераль хезмәте 2021 елда үткәрелгән халык санын исәпкә алу нәтиҗәләрен игълан итте. Билгеле булганча, чираттагы җанисәп 2020 елда узарга тиеш иде. Әмма пандемия аркасында ул кат-кат күчерелде. Шуңа күрәме, ыгы-зыгыда оештырылган бу эшнең нәтиҗәләрен шик астына куючылар да шактый. Тик монысы – сөйләшү өчен аерым мәсьәлә. Саннарга әйләнеп кайтыйк.

Соңгы унбер елда илдә яшәүчеләр саны, 4,3 миллион кешегә артып, 147,2 миллионга җиткән. Моңа 2014 елда Кырым һәм Севастопольнең Россиягә кушылуы да тәэсир итте, дип ачыклык керткән белгечләр. Алдагы җанисәп белән чагыштырганда, илдә 18 шәһәр, 33 авыл барлыкка килгән. Ни кызганыч, 25 меңгә якын авыл (гомуми күрсәткечнең 27,5 проценты. – **Ред.**) ташландык хәлгә килгән.

Татарстанда яшәүче кешеләр саны – 4 миллион 4809. Шул исәптән, 3 миллионнан артык кеше – шәһәр халкы. Ике җанисәп арасында Татарстан халкы 218321 кешегә арткан. Алар арасында татарлар 78604 кеше тәшкил итә. Республикада яшәүче халыкларның 52 проценты – татарлар. Тик ил күләмендә милләттәшләребез 597 меңгә кимегән. 2012 елда үткәрелгән халык санын исәпкә алу барышында 5 миллион 311 мең кеше үзен «татар» дип атаган булган. Халык санын исәпкә алуда катнашкан 16,5 миллион кеше, гомумән дә, милләтен күрсәтүдән баш тарткан.

Соңгы мәгълүматларга караганда, илдә «татар телен беләм» дип фикер йөртүчеләр саны 1 миллион кешегә кимегән. 2010 елда андыйлар саны 4,3 миллион кеше тәшкил иткән. Татар теле таралуы ягыннан ил күләмендә, рус һәм инглиз телләреннән соң, өченче урында тора. 2021 елда үткәрелгән халык санын исәпкә алу барышында Россия халыклары телләрен белү һәм аны көндәлек тормышта куллану турында аерым да сорашканнар. Саннарга караганда, татар телен 3 миллион 261 мең 155 кеше белә. Ә менә көндәлек тормышта аны 2,9 миллион чамасы кеше куллана. Гомумән алганда, җанисәп барышында үзен «татар» дип атаучыларның 86 проценты татар телен туган теле дип атаган. Соңгы унбер елда андыйлар саны 6 процентка арткан. Ә менә «татар телен беләм» дип җавап бирүчеләр саны 11 процентка кимегән.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Данис ШАКИРОВ, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе:

– Халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре турында сөйләгәндә, иң элек шуны әйтәсем килә: без Россия халыклары арасында үзебезнең икенче урыныбызны саклап калдык. Икенчедән, Бөтендөнья татар конгрессының экспертлары бәяләмәсе нигезендә һәм соңгы ун ел эчендә үзебез алып барган эшчәнлеккә, төрле сораштыру нәтиҗәләренә таянып ышандырып әйтә алам: илебездә татарларның саны 5,5 миллион кешедән дә ким түгел. Соңгы ун ел эчендә Татарстанның да, татар халкының да абруе дөньякүләм дәрәҗәдә артты. Һәм милли аңыбыз да югары дәрәҗәдә. Мин моны инанып әйтә алам. 2013 елда Казанда үткәрелгән Универсиада, 2015, 2018, 2019 елларда республика тарафыннан уздырылган дөнья чемпионатлары, 2020 елда югары дәрәҗәдә узган ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итү Татарстанны да, татар халкын да дөнья күләмендә тагын да югары дәрәҗәгә күтәрде.

Безнең саннарның ни өчен Росстат мәгълүматлары белән тәңгәл килмәвенең сәбәпләренә килгәндә, барыбыз да беләбез: халык санын исәпкә алу вакыты пандемия чорына туры килде. Саннарга игътибар итегез: моңа кадәр 2010 елда үткәрелгән халык санын исәпкә алу барышында илдә яшәүче 5,6 миллион кеше үзенең милләтен күрсәтмәгән. Ә 2021 елгы нәтиҗәләр буенча әлеге күрсәткеч 16,5 миллион кешене тәшкил итә. Җитешмәгән татарлар санын да шуннан эзләгез. Мәкерле дошман – ковид һәм пандемия аркасында әлеге җанисәпне үткәрү вакыты ике тапкыр үзгәрде. Шуңа күрә дә безнең барлык халкыбызга да барып җитмәгәннәр. 16,5 миллион кеше арасында башка милләт вәкилләре дә бар, билгеле. Безнең татарларыбыз да шунда. Тагын бер тапкыр әйтәм: Россиядә татарлар саны 5,5 миллион кешедән дә ким түгел. Без җанисәпкә бик әзерлекле килдек. Күзәтүләр дә, сораштыру нәтиҗәләре дә бар. Халкыбызның милли үзаңын һәрвакыт тоябыз. Былтыр, Татар конгрессының 30 еллыгы кысасында уздырылган VIII съездда катнашырга дип, 45 чит илдән һәм илебезнең 81 төбәгеннән килгән делегатлар моны тагын бер кат раслады. Бу мәсьәлә һәрбер төбәк буенча Бөтендөнья татар конгрессының гыйнвар аенда узачак Милли шура бюросында һәм Бөтендөнья татар конгрессының март аенда узачак Милли шура утырышында аерым яссылыкта каралачак.

Дамир ИСХАКОВ, галим, этнограф, тарих фәннәре докторы:

– Мин гомерем буе халык санын исәпкә алу белән шөгыльләнәм. Моннан чыгып шуны әйтә алам: җанисәп бар яктан да канәгатьләндерерлек була алмый. Моңа бәйле проблемалар гел чыгып торды. Тик илнең күренекле демографлары әйтүенчә, 2021 елда үткәрелгән халык санын исәпкә алуның кимчелекләре гадәттәгедән күбрәк булды. Җанисәп нәтиҗәләрен күпмедер дәрәҗәдә әнә шуның белән дә аңлатып була. Уйлап карагыз, 16,5 миллион кешенең милләте дә, туган теле дә юк. Бу кешеләргә халык санын исәпкә алучылар гомумән килмәгән, бары тик шул гына. Ә алар турында мәгълүматны полиция чыганакларыннан алганнар. Гамәлдәге канун нигезендә бу өлкәдә кешенең милләтен теркәргә ярамый. Бүген татарлар күбрәк зур шәһәрләрдә яши. Җанисәпкә бәйле кимчелекләр дә нигездә зур шәһәрләргә бәйле. Халкыбыз беркая да югалмаган, аларны исәпкә генә алмаганнар.

ИМИНЛЕК САГЫНДА

12 гыйнвар – Прокуратура хезмәткәрләре көне. Татарстан Премьер-министры Алексей ПЕСОШИН прокуратура органнары хезмәткәрләрен һәм ветераннарын һөнәри бәйрәмнәре белән котлады.

«Татарстан Хөкүмәте исеменнән сезне Прокуратура хезмәткәрләре көне уңаеннан котлыйм, – диелә котлауда. – Россия Прокуратурасы – хокук саклау системасының дәүләт һәм иҗтимагый иминлек сагында торучы төп институтларыннан берсе. Прокуратураның иң яхшы вәкилләре һәрвакыт югары дәрәҗәдә һөнәри осталыгы, бурычына тугрылыгы, фидакарьлеге белән аерылып тора.

Бүгенге гаять катлаулы тышкы сәяси һәм икътисадый вазгыятьтә кешеләребезнең конституцион хокукларын, ирекләрен яклау-саклау, коррупциягә, террорчылык, экстремистлыкка каршы көрәшү прокуратура хезмәткәрләре өчен өстенлекле бурыч булып тора.

Республика җитәкчелеге авыр, әмма изге хезмәтегез, законлылык һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүегез өчен рәхмәт белдерә.

Сезгә һәм якыннарыгызга чын күңелдән нык сәламәтлек, бәхет, шатлык, иминлек, яңа үрләр, гаиләләрегездә татулык телим!»

Елама син, тәрәзә!

Көн үсәсен төн үсә… Бу көннәрдә «елак» пластик тәрәзә төпләрендә каткан бозга карап, әнә шулай уфтанучылар саны бермә-бер артты. Буйыйсы юк, карыйсы юк, озак хезмәт итә дип, агач рамлы тәрәзәләргә бик тиз алмашка килгән пластик тәрәзә салкынга гына бирешәме, әллә аның сыйфаты елдан-ел начараямы? Тәрәзә төбе катса, нишләргә?

Бүген агач рамнар – сирәк күренеш. Булса да, авыл җирендә. Әле анда да җылыны яхшы саклый, урамдагы тавыш ишетелми дип, пластик тәрәзәгә өстенлек бирәләр. Шәһәрдә исә әйтеп торасы да юк. Кайсы гына йортка карама, пластик тәрәзәләр тезелеп киткән. Җитештерүчеләр дә мактап туймый, 20–25 елга кадәр хезмәт итә, дип ышандыралар. Тик менә кыш җиткәч, аларның кимчелекләре искә төшә. Агач рамнар белән чагыштырганда, пластиктан ясалганнары һава үткәрми, шуңа күрә еш парлана.

– Тәрәзә рамнары өчен электән үк сыйфатлы агачлар гына файдаланганнар. Авылда иске тәрәзә рамнарын агачка кисәм дисәң дә, пычкы үтми. Ә андый материал бик кыйммәт. Шуңа күрә чагыштырмача арзан пластик тәрәзәләргә өстенлек бирәләр дә инде, – ди агач остасы Мансур Шәйхетдинов.

Башкалада пластик тәрәзәләр урнаштыру белән шөгыльләнүче оешма хезмәткәре Зөлфәт Мансуров әйтүенчә, тәрәзәләр парлану – сыйфаты начар дигән сүз түгел.

– Өйдә яки фатирда пластик тәрәзә урнаштырганнан соң, бүлмәдә микроклимат, ягъни һава температурасы, дымлылык, һава йөреше үзгәрә. Дым күбрәк булган саен, тәрәзәләргә «чык төшә». Моны булдырмас өчен, иң беренче чиратта, тәрәзә тирәсен җылылык белән тәэмин итәргә кирәк. Хуҗабикәләр, бигрәк тә гөл үстерергә яратучылар, бездән киң тәрәзә төбе куюны сорый. Тик болай эшләргә ярамый. Тәрәзә төбе никадәр киңрәк булса, җылылык шулкадәр начаррак менә. Бүлмәдә дымлылык күләмен карап-тикшереп торырга һәм һава алмашынуны тәэмин итәргә кирәк. Тәрәзәләргә эленгән калын пәрдәләр дә парлану яки боз катуга китерә, – ди белгеч.

Аның сүзләренә караганда, кыш җиткәч, инде моңа кадәр үк урнаштырылган тәрәзәләрнең сыйфатыннан зарланып шалтыратучылар арта.

– Гарантия вакыты чыкмаган булса, пластик тәрәзәләрнең кимчелекләрен төзәтергә үзебез барабыз. Әлеге өлкәдә ун елдан артык эшләгән кеше буларак шуны әйтәсем килә: тәрәзәләрнең төзексез булуы аркасында дым җыелу очраклары бик сирәк, унга бер дә туры килми. Еш кына хуҗалар тәрәзәләрнең режимын алмаштырырга оныта. Пластик тәрәзәләр, ел фасылына карап, җәйге һәм кышкы режимга көйләнгән. Җәйгесендә, мәсәлән, тәрәзә һәм ишекләрне япканда, һава йөрсен өчен ара кала. Ә шул ук тәрәзәне кышкы режимга күчерү өчен, аның фурнитурасын шөреп боргыч белән көйләп җибәрү дә җитә. Моны һәркем үзе эшли ала, – ди Зөлфәт Мансуров.

Хуҗабикә Асия Закирова исә «елак» тәрәзәләрдән котылуның үз җаен тапкан.

– Безнең өйдә пластик тәрәзәләр тора. Салкыннар башлангач, автомобиль тәрәзәләре парланмасын өчен файдаланыла торган махсус сыекча белән яхшылап сөртәм. Атнага бер тапкыр юып чыгарам да, тәрәзә төпләре коп-коры тора, – ди хуҗабикә.

ТИКШЕРГӘННӘР ДӘ ТИКШЕРЕЛӘ

«КОРАЛ ТУРЫНДА»ГЫ ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОНГА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТЕЛДЕ

Яңалык

Булганын да алырга мөмкиннәр, ә хәмер кулланганлыкны медицина тикшерүеннән баш тартучыларга бөтенләй бирмәячәкләр. «Корал турында»гы федераль закондагы яңалыкларның берничәсе генә әле бу. Законга үзгәрешләр кертү турындагы документны Россия Президенты Владимир Путин узган елның 29 декабрендә имзалады.

«Татар-информ»

«Корал турында»гы федераль закон әледән-әле үзгәреп тора. Хәер, моның өчен сәбәпләр дә җитәрлек. Ерак барасы юк: 5 гыйнвар кичендә Җәлил бистәсендә яшәүче бер ир-ат саксызлык белән танышын атып үтергән. Россия Тикшерү комитетының Татарстан буенча тикшерү органнары тарафыннан 37 яшьлек ир-атка карата «Саксызлык буенча үлемгә китерү» маддәсе буенча җинаять эше кузгатылган. Тикшерүчеләрнең сүзләренә караганда, әлеге ир-ат 30 яшьлек танышы белән Сарман районында куян һәм кыр кәҗәсенә законсыз ауга чыккан. Коралга лицензияләре дә булмаган, ИЖ-27 ау мылтыгын да кемнәндер алып кына торганнар. Ирләр, кыр кәҗәсен аткач, кар чанасына утырып, яраланган хайван янына барган. Шуннан соң 37 яшьлек ир хайванга тагын бер тапкыр атмакчы булган, әмма пуля ялгыш алда утырган танышының баш артына тигән. Ул шундук җан биргән. Атучы үз гаебен таныган, билгеле. Хәзерге вакытта бу хәлнең барлык нечкәлекләрен ачыклау буенча тикшерү эше алып барыла.

Закондагы үзгәрешләр нидән гыйбарәт соң? Беренчедән, тәүге тапкыр корал алырга җыенучылар беренчел тикшерү узарга тиеш булачак. Моңарчы тикшерми генә биргәннәрмени, дияргә ашыкмагыз: бу юлы нәтиҗәне, сәламәтме-юкмы, дип кенә түгел, ә башкаларның хокук һәм ирекләрен бозу, шулай ук дәүләт һәм җәмгыять иминлегенә куркыныч тудыру ихтималын да исәпкә алып ясаячаклар. Закон текстында әйтелгәнчә, бу тикшерүне эчке эшләр органнары яки ФСБ хезмәткәрләре (оператив-эзләү органнары да җәлеп итәргә мөмкин) уздырачак. Тикшерүне узмаган, ягъни корал бирү куркыныч, дип табылган очракта, лицензия бирелмәячәк. Әмма бу тыюның гамәлдә булу вакыты ике ел гына. Әлеге вакыт үтү белән, тикшерүне яңадан узып карарга мөмкин булачак. Искәрмәләр дә бар: хәрби хезмәткәрләргә һәм илдәге аз санлы халык вәкилләренә бу тикшерүне узу мәҗбүри түгел.

Тагын шунысы мөһим: коралга лицензиясе булган кешеләрне дә шушы рәвешле тикшерергә мөмкиннәр. Нәтиҗәсе канәгатьләндерерлек булмаса, ул кешедән лицензия алыначак.

Икенчедән, тагын берничә категориягә керүчеләргә корал сатып алу өчен лицензия бирелмәячәк. Болар:

– җинаять эше фигурантлары – шикләнелүчеләр яки аңлы рәвештә җинаять кылуда гаепләнүчеләр;

– суд тарафыннан билгеле бер нигезләр буенча (җәзасын үтәмәгән килеш тә акланган яки җәза бирү срогы узган очракта) аңлы рәвештә кылынган җинаять җаваплылыгыннан азат ителгәннәр;

– хәмер кулланганлыкны медицина тикшерүеннән баш тарткан өчен административ җаваплылыкка тартылучылар.

Өченчедән, мобилизацияләнүчеләр һәм үз теләкләре белән махсус хәрби операциядә катнашучылар үзләрендә булган коралларын Росгвардия яки эчке эшләр органнарына яңа закон нигезендә бушлай саклауга тапшыра алачак.

Дүртенчедән, яңа документта Мәскәү метрополитенына ведомство сагы булдыру да рөхсәт ителә. Һәм закон аның хезмәткәрләренә пилотсыз очкычлар белән көрәш вәкаләтләрен дә бирә.

Әлеге федераль закон рәсми рәвештә 10 гыйнварда басылган. Үз көченә ул 90 көн узганнан соң керәчәк.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

СӨЛЧӘБАШ ӨЯНКЕЛӘРЕ

ШӘҖӘРӘ

«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты оештырган «Без тарихта эзлебез» бәйгесендә Чистай районы данын Шәрифуллиннар гаиләсе яклады.

Әйтергә кирәк, бу бәйгедә юкны бар итәргә тырышып кына катнашып булмый. Тамырларың нык, тарихың бай, балаларың күп, эшләгән эшләрең киләчәккә калдырырлык булып, һәрьяклап башкаларга үрнәк тә булырга тиешсең. Бу бәхетле гаилә дә шундыйлардан. Әмма кара кайгы килгән чаклары да күп була аның.

Зәрә белән Нургата Шәрифуллиннар, яңа өлгерткән йортларын ташлап, узган гасырның алтмышынчы еллар башында чыгып китәләр Сөлчәбаштан. Аларны авыл башындагы өянкеләр озатып кала...

Гаилә тарихы бик матур башлана. Авылдагы кичке уенда танышкан егет белән кыз 1939 елның ноябрендә язмышларын бергә бәйли. Яңа гаиләгә сөенеч булып, 1940 елның ноябрендә уллары Сәгыйть дөньяга килә. Тик сабый «әти» дип әйтергә өлгерми дә кала, Нургата беренче көннән үк сугышка китә. Озак та үтми, «хәбәрсез югалган» дигән кара кәгазь дә килеп төшә. Тик Зәрәсе ышанмый бу хәбәргә, исән-сау кайтсын дип, төннәр буе догалар укып чыга. Көндез вакыты юк: ир-атлар калмагач, 19 яшьлек Зәрәне бригадир итеп куялар. Чая, үткен булганга, бу авыр йөкне тарта алыр дип өметләнгәннәрдер инде. Әмма тәҗрибә булмагач, төрле хәлләргә юлыга кыз. 1942 елда сыерлар арасында тилчә чире таралгач, әздән генә трибуналга эләкми кала. Авылдашлары коткара аны. Районнан килгән тикшерүчеләрне: «Яшь бит, тәҗрибәсе, белеме дә юк, җитмәсә ире хәбәрсез югалды, ялгызы гына сабые белән каенанасын тәрбияли», – дип үгетлиләр. Ачка үлмәсен дип, улы Сәгыйтьне биш яшенә кадәр имезә Зәрә. Көтелмәгән сөенеч булып, әсирлеккә эләккән Нургата да туган йортына аяк баса.

Хәзер инде аларның ни өчен туган туфрактан аерылып киткәннәрен белеп тә бетермиләр. Мөгаен, Никита Хрущев җитәкчелек иткән чорда авыл хуҗалыгына булган басым белән ризалашмаганнардыр дип уйлыйлар. 1968 елда Чистай районындагы Йолдыз бистәсенә килеп төпләнә алар. Эчәр сулары, ашыйсы ризыклары шунда була, күрәсең. Гаиләдә сугыштан соң, тупырдашып, тагын 12 бала туа.

Борынгыдан килгән гадәт буенча, нәселнең ир-егетләре җир эшенә тугры булганнар. Чирәм җирләрне күтәрүдә дә катнашканнар. Гаиләдә шулай ук табиблар, укытучылар, төзүчеләр, башка төрле һөнәр ияләре дә бик күп. Нургата белән Зәрәдән башланган шәҗәрә агачына хәзер 30 онык, аларның 29 баласы, оныкчыкларының 2 баласы исеме язылган. Яшәгән җирләренең географияләре дә бик киң: 3 ил – Россия, Төркия, Казахстан. Россиядә 7 шәһәр – Мәскәү, Иваново, Пермь, Уссурийск, Владивосток, Самара, Санкт-Петербург, Татарстанда 6 төбәк – Казан, Чистай, Чаллы, Түбән Кама, Болгар, Балтач. Шәрифуллиннарның хезмәт сөючән нәсел икәнлеген хөкүмәтебез биргән бүләкләр дә раслап тора. Спас, Чистай районы кырларында мул уңыш җыеп, Җәмил, Рафаил, Әнвәр алдынгы игенчеләр исемлегендә. Гөлсирә Чистай үзәк хастаханәсендә «Иң яхшы акушер» исеменә лаек булган. Гөлчирәләре исә шунда ук «Иң яхшы лаборант» исемен алган. Киленнәре Альмира – Йолдыз урта мәктәбенең югары категорияле тарих укытучысы – «Яңа чор педагогы» исеменә лаек булса, аларның Рафаил белән үстергән кызлары Зилә «Чистай гүзәле» бәйгесендә җиңеп чыккан. Болары – һөнәри бәйгеләрдә җиңүчеләр генә әле. Моннан тыш төрле елларда орден-медальләр белән бүләкләнгән, мактаулы исемнәр бирелгән туганнарның исәбе-саны юк. Арада хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар да бар. Җәлил хәрби конфликтларны юкка чыгаруда катнашу өчен биш тапкыр Чечняга бара. Күрсәткән батырлыклары өчен биш медаль белән бүләкләнә. Бүген аның эшен улы Рөстәм дәвам итә. Ул – Украинадагы хәрби операция зонасында. Шәрифуллиннар нәселе уку йортларын «5ле» билгесенә генә тәмамлаган оныклары белән дә горурлана.

Бүген Йолдыз бистәсендә 13 бала тәгәрәшеп үскән нигездә уллары Рафаил белән киленнәре Альмира гомер итә. «Бик еш булмаса да, Сөлчәбашка кайтып, әти-әниләр, әби-бабайлар туган авылның исен иснәп, анда яшәп яткан туганнарның хәлен белеп киләбез», – ди Альмира ханым.

Шәрифуллиннар ике нигезне дә кадерләп саклый. Сөлчәбашта әтиләре Нургатаның энесенең улы Рифкат белән Рәсимә яши. Фестиваль өчен әзерләгән чыгышларында да ике авыл өчен янып торулары бик ачык сизелә. Сәхнәгә чыккан оныклары Инсаф: «Мин куркам. Ялгыз каласым килми», – дип югалып калгач та, әнисе аны болай тынычландыра: «Курыкма, улым. Син беркайчан да ялгыз булмассың. Борылып кара әле: син зур нәселебез канаты астында. Үзең дә шушы нәсел агачына өлешеңне кертерсең». Бу хәлне күргән Инсаф: «Болай булгач, мин дә төп йортка килен алып кайтам, димәк», – дип хыялланып та ала әле. Сәхнәгә чыккан оныклар җәйне көтә. Нигә дисезме? Бергәләп әби-бабайлар йөргән сукмакларны таптарга. Әнә бит алар нинди күбәү: Таһир, Ләйлә, Руслан, Әдилә, Камилә, Лилия, Айрат, Айдар... Кыскасы, санап бетерерлек кенә түгел. Гаиләнең буыннан буынга күчеп барган ядкәре дә төп нигездә саклана. Ул – тартмага салынган дисбе. Зәрә әбиләренә аны әнисе Миннехәят биргән. Нургата бабалары сугышка китеп, әсирлеккә эләккәч, төннәр буена елый-елый тарткан ул дисбене. Сандыкта тагын бик күп дисбеләр ята. Альмира ханым аларны туганнарына бүләк итәр өчен ясый. Зур эшләр башкарган ул. Йолдыз бистәсенең тарихын өйрәнеп, үзе укыткан мәктәптә Туган якны өйрәнү музеен эшләтеп җибәргән. «Фестивальнең дә нык файдасы тиде. Туганнар белән янә бер кат аралашып, бик күп истәлекләргә тап булдык, рәхәтләнеп сөйләштек. Әнә шуңа күрә дә мин оештыручыларның эшен бик югары бәялим. Бигрәк тә район җитәкчеләренә, аерым алганда, бу бәйгедә катнашырга тәкъдим ясап, ахырынача гел ярдәм итеп торучы, районда мәдәният эшләрен алып баручы Ольга Рыжовага рәхмәтләремне җиткерәм. Чыгыш ясарга нәселебездән 20ләп кеше барды. Еракта яшәү сәбәпле кайта алмаганнар видеолар төшереп җибәрде», – дип сөйли Альмира ханым.

Шәрифуллиннарның кайбер гаилә ядкәрләре дә музейда саклана. Бәләкәйрәк оныклар кайчакларда: «Нишләп безнең әйберләребез анда куелган?» – дип сорыйлар да икән. Әти-әниләре аларга, горурланып: «Безнең гаилә тарихы ул – ил тарихы», – дип җавап бирә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КӘРӘКӘНЕ – КЕРОСИН, КАРПНЫ БОРЧАК БЕЛӘН АЛДЫЙСЫҢ

САБАДА БАЛЫКЧЫЛАР ЯРЫШЫ УЗДЫ

«Үрмәкүч оясында булса, балык шәп эләгә». Саба районында яшәүче 72 яшьлек балыкчы Вакыйф Җамалиев моны үз тәҗрибәсеннән чыгып әйтә. Күптән түгел узган балыкчылар ярышында ул районның иң өлкән балыкчысы булып танылган. Иң яше – Рүзәл Садыйков. Шулай ук иң зур, иң күп балык тотучылар да бүләксез калмаган.

Саба балыкчылары Чулман елгасының «Ташбака» дип йөртелгән урынында егерме өченче мәртәбә ярыш уздырган. Анда быел 93 кеше катнашырга теләк белдергән. Ярышка Теләче балыкчылары да кушылган. Бәйгене оештыручы Хәниф Тимербаев әйтүенчә, балыкчылар елдан-ел күбәя, гаиләләре белән йөрүчеләр дә бар. Элек хатын-кызлар да катнашкан, тик соңгы вакытта ирләр генә җыела икән. Иртән башланган ярыш кичкә кадәр дәвам иткән. Бәкедән иң зур сыла (берш) балыгын Юлбаттан Назыйф Шакирҗанов, иң зур судакны Газинур Вафин тартып чыгарган. Зурлыгы – 2 кило чамасы.

Балыкчыларны башка сынаулар да көткән. Бозны тиз арада бораулап тишүдә Раил Садыйковка тиңнәр булмаган. Моточаналар ярышында финишка беренче булып Салават Шиһапов килгән. «Иң-иң»нәргә мактау кәгазьләре, иганәчеләрнең кыйммәтле бүләкләре тапшырылган. Балык тоту өчен кирәк-ярак белән сәүдә итүче кибет хуҗалары булышкан.

Балыкчыларга хәл-әхвәл белешү, тәҗрибә уртаклашу өчен дә кирәк мондый очрашу. Үзләре әйтүенчә, ярышларның балыклар өчен дә файдасы бар. Бәкеләрдән алар кислород сулый, бу вакытта аңа бик мохтаҗ булалар икән.

Иң өлкән балкычы дип танылган Вакыйф абый Җамалиев 7 яшьтән үк кармак сала. Хәзер инде аның 65 ел стажы бар. Якутиядә яшәгәндә, хәтта 40 килолы тайменьнар эләктергән. Чуртаннарының иң зурысы – 16, корбан балыгы (лещ) – 5, кызылканаты – 2,5 килолы.

– Елгага төштең дә кармак салдың гына түгел. Һәр балыкның – үз хәйләсе. Саба егетләрен дә балык тоту серләренә өйрәтеп бетердем. Моның өчен китап күп укырга кирәк. Кешегә карап та өйрәнәсең. Җимнән дә күп нәрсә тора. Ерткыч балыкка икенче төрлене әзерлисең. Карпка борчак кирәк, кәрәкә керосин, әнис тамчысы, сарымсак исен ярата. Шуңа күрә рюкзакта суалчаны да, башкасы да булырга тиеш. Елга, күл буенда берничә урында төрле җимне ашатып, кайсы яхшырак дип тикшереп карыйм, – дип сөйли балыкчы абзый.

Балык капмаган чаклары бик сирәк була аның. Моңа иптәшләре дә аптырый. Кайчакта, үзеңә бер төрле җим аласың, безгә икенчесен бирәсең, дип үпкәлиләр дә икән. «Андый гадәтем юк. Мин алдаласам, әнә алайса китап укыгыз, дим», – ди ул.

Вакыйф абый балыкка барганда, ырымнарга да ышана. Әгәр үрмәкүч пәрәвездә булса, табыш булачак, аннан чыгып качса, су буена төшүдән мәгънә юк, ди. Шул үрмәкүчкә карап, буран, җилләрдә дә уңыш белән кайтканы бар аның. Эт аунаса, һава торышы үзгәрә. Карлыгачлар астан очса да, буш кул белән кайтачаксың. Менә шундый вак нәрсәләргә дә игътибар итә ул.

Сабырлыгың җитмәсә, яр кырына килеп тә торма! Заманасында көрәшеп йөргән, тормышта кызурак холыклы Вакыйф абый бәке янында бөтенләй икенче кешегә әйләнә. Кайсы җирең генә авыртса да, 3–4 сәгатьтән бернинди дару да, табиб та кирәкми башлый, ди.

– Ярга бик якын килергә ярамый, балык тавышны яратмый. Кармак салгач, тыныч кына утырырга кирәк, – ди ул. – Балык, дип өйдәгесен онытмагыз. Барлык эшләрне карап бетергәч кенә барыгыз. Монысы, кайткач, хатын белән ызгышмас өчен. Яшь балыкчыларга шулай дип әйтәм, истә тоталар. Әгәр өйдә булышмасаң, тоткан балыгың да булмаса, тавыш чыгар өчен күп кирәкми.

Кышкы ярыш үткәч, җәйгесенә әзерләнә башлаганнар. Анысында балык та тотачаклар, моторлы көймәләрдә дә ярышачаклар.

Сәрия МИФТАХОВА



Галимҗан Нигъмәти

1926–1927 ЕЛЛАРДА БАШ МӨХӘРРИР БУЛЫП ЭШЛӘГӘН

Галимҗан Нигъмәтинең дә гомере фаҗигале тәмамлана. Ул – утызынчы елларда совет режимы оештырган һәм өч дистәдән артык татар язучысының, журналистының гомерен өзгән дәһшәтле репрессия корбаннарыннан берсе.

Аны 1937 елның 16 сентябрендә кулга алалар һәм троцкийчы контрреволюцион оешмада әгъза булып торуда гаеплиләр. Берничә елга сузылган «тикшерү» барышында галим Казан һәм Алабуга төрмәләрендә утыра. 1940 елның 17 гыйнварында махсус «өчлек» әдипне биш елга ирегеннән мәхрүм итә. Шул хөкем карары нигезендә Галимҗан Нигъмәтине Устьвымлаг исемле тоткыннар лагерена җибәрәләр. Шунда ул, ачлыктан, хәлсезлектән булса кирәк, 1941 елның 4 декабрендә вафат була һәм хәзерге Коми Республикасының Княжепогост районындагы Весляна тимер юл станциясеннән 16 чакрым ераклыкта урнашкан Вожаель бистәсе зиратына күмелә.

Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәтуллин 1897 елның 26 июлендә хәзерге Башкортстан Республикасының Чишмә районы Үдрәкбаш (Өйдерәкбаш) авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Галимҗанга ике яшь чагында аның әтисе, гаиләсен алып, Уфа шәһәренә күчә һәм шунда төпләнеп кала. Төрле төзелешләрдә гади эшче булып көн күргән һәм гаилә тормышын җайлаган Әмирҗан агай улын укытырга тырыша: башлангыч белем алуга, Галимҗанны Уфаның алдынгы мәдрәсәләреннән булган «Галия»гә урнаштыра. Галимҗан анда бик тырышып укый. Соңгы сыйныфларда чагында ул инде үзе дә түбән сыйныф шәкертләренә әдәбияттан дәресләр бирә башлый.

1917 елгы Февраль һәм бигрәк тә Октябрь инкыйлабларын илдә яңа чор башлану дип кабул иткән егет беренче көннәрдән үк җаны-тәне белән яңа тормыш төзүчеләр сафына баса. Гражданнар сугышы башлангач, Уфада татар телендә нәшер ителгән «Кызыл яу» газетасында әдәби хезмәткәр вазыйфаларын башкара. Уфаны Колчак гаскәре алу куркынычы тугач, редакция белән бергә Бәләбәй шәһәренә, аннан Омскига күченә, соңгысында ВКП(б)ның Көнбатыш Себер крайкомы органы «Азат Себер» газетасында башта сәркатип, аннары җаваплы мөхәррир булып эшли.

1921 елны Галимҗан Нигъмәти, белемен арттыру нияте белән, Мәскәүгә килә һәм, Шәрык хезмәт ияләренең коммунистик университетында берьеллык курсны тәмамлап, Дәүләт журналистика институтында укый башлый. Әмма Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты аппаратына милли матбугат буенча инструктор итеп билгеләнүе сәбәпле, аңа укуын өзәргә туры килә.

1926 елның ахырларында Галимҗан Нигъмәти Казанга җибәрелә һәм «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасына баш мөхәррир итеп билгеләнә. 1928–1930 елларда ул Татар дәүләт нәшриятының баш мөхәррире була, бер үк вакытта Көнчыгыш педагогия институтында татар әдәбияты тарихыннан лекцияләр укый. Аннан институтның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, соңрак кафедра мөдире булып эшли. 1935 елда аңа профессор исеме бирелә. 1930–1932 елларда Галимҗан Нигъмәти, институттагы төп эшеннән аерылмыйча, Татарстан пролетар совет язучылары федерациясенең матбугат органы «Яңалиф» журналының җаваплы мөхәррире вазыйфаларын да башкара.

Бу елларда Галимҗан Нигъмәтинең иҗатында әдәбият белемендәге проблемалар аеруча зур урын били. Алар тәнкыйтьченең «Революция елларындагы әдәбиятыбыз», «Әдәбият һәм тормыш», «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре», «Татар совет әдәбияты күтәрелештә», «Татар совет драматургиясенең үсеше» кебек күләмле мәкаләләрендә һәм китапларында яктыртыла. Аның бу хезмәтләрендә, әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә татар язучыларыннан Мәҗит Гафури, Гафур Коләхмәтов, Дәрдмәнд, Шәехзадә Бабич, Кави Нәҗми, Һади Такташ, Афзал Шамов, Ибраһим Гази кебек язучыларның иҗатлары анализлана. Ул рус классикларыннан Лев Толстой, Антон Чехов, Максим Горький иҗатлары турында да мәкаләләр яза. Галимҗан Ибраһимов иҗатына махсус берничә мәкалә багышлый. 1936 елда Габдулла Тукайның тууына 50 ел тулу уңаеннан «Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы» дигән хезмәтен язып бастыра.

Педагог буларак, Галимҗан Нигъмәти татар әдәбияты фәне буенча югары квалификацияле белгечләр әзерләү эшенә күп көч куя. Танылган филология фәннәре докторлары Мөхәммәт Гайнуллин, Хәмит Ярми, Гали Халит, филология фәннәре кандидатлары Җамал Вәзиева, Якуб Агишев, Мөхәммәт Мамин, Гази Кашшаф, шагыйрь-әдипләрдән Сибгат Хәким, Абдулла Алиш, Абдулла Әхмәт, Идрис Туктаров, Сөббух Рәфыйков, Ибраһим Сәлахов һәм башка югары белемле укытучылар, мәдәният эшлеклеләре – һәммәсе Галимҗан Нигъмәтинең шәкертләре.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

КОТЛЫЙБЫЗ!

Янгын сүндерүдәге батырлыгы һәм фидакарьлеге өчен **Палатов** Артур Амруллаевич Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Янгын сүндерүдәге батырлык өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Россия Федерациясе җыелма командасын Грац шәһәрендә (Австрия Республикасы) үткәрелгән «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча Европа чемпионатына уңышлы әзерләүне тәэмин иткән өчен «Транснефть-Прикамье» акционер җәмгыяте инженеры **Минеев** Альберт Эдуард улына Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президенты Рәхмәте** белдерелде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Дарвин теориясе» маркетинг коммуникацияләре агентлыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Кутилов** Владимир Леонидовичка; «Берләштерелгән Шәһәрләр һәм Җирле Хакимиятләр Бөтендөнья оешмасының Евразия төбәк бүлеге» Халыкара ассоциациясе генераль секретаре **Сәгыйтов** Расыйх Кадыйм улына Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президенты Рәхмәте** белдерелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе, әнисе **МОРАТОВА Роза Зәки кызы** вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Моратов Марат Яшәр улының авыр кайгысын уртаклаша.

«Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте коллективы, **әнисе** кинәт вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының инвестицион сәясәт һәм максатчан программалар бүлеге җитәкчесе Гафуров Илдар Шәүкәт улының, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте коллективы, **әтисе** кинәт вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры Шадриков Александр Валерьевичның авыр кайгысын уртаклаша.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Хайван

– Хайван! – дип кычкыра күрше хатыны ачык тәрәзә аша... Ирен сүгә инде...

Хайваннарны яратам мин. Башкача булуы мөмкин дә түгелдер. Фермада маллар арасында үскән малай ич. Сыерлар, бозаулар, сарыклар, атлар һәм... малчылар авызыннан чәчрәп торган «мат»лар арасында. Хәер, мин аның «мат» икәнен дә үсә төшкәч кенә аңладым әле. Ул вакытта безнең телебез шундый, ә башкалар бик үк дөрес сөйләшми сыман тоела иде. «Хайван» сүзенең дә чын мәгънәсен шул чордарак төшендем. Югыйсә мин аны кәефеңә туры килмәгән кешегә карата әйтелә торган сүз дип йөри идем.

Ә хайваннар күңелле иде. Утар буйлап: «Мә, мә... Мә!» – дип йөрүче сарыкларның юмартлыгына соклана идем. Ничек кенә мактасак та, совет чорында да гел «давай» диләр иде. Сөт давай! Йон давай. Күрсәткеч давай. Давай да давай, бир дә бир. «Мә» диюче юк. Сарыклардан башка. Хәзер болай «мә» диюче бар ул. Бөтен нәрсәне дә «мә» дип кенә торалар. Кайчагында тормыш үзе дә сарык утарына охшап китә: бөтен яклап «Мә, мә... Мә!» – дип кычкыралар. Тик боларның берсе дә сарык түгел, берсе дә бушка бирми.

Ул бозаулар!.. Бозаудан да назлырак җан иясе юк. И, аның беренче тапкыр урамга чыгуын күрсәң! Капкадан атылып чыга да кинәт туктап кала. Һәм аптырап карап тора. Мин хәтта аның бу мизгелдә нәрсә уйлаганын да аңлыйм кебек. «Ну, яп-яланаяк! Кая килеп эләктем мин, анаңы сатыйм?! Что за...» Шул чамарак уйлый ул. Башкача уйлый алмый, ул да малчыларны тыңлап үскән ич. Бераз һушына килгәч: «Ни фига себе! Нинди иркенлек!» – дип башын селкеп ала да күзе нәрсәгәдер төшә: «Монысы нәрсә тагын? А-абзарыңны себерим!» – дип, тегенең артыннан ияреп китә. Аңа барысы да кызык, барысы да яңа. Нәрсә күрә – шуның артыннан ияреп китә. Борынын тидереп карый, ялап карый. Берәүгә дә әйтмәсәгез, сезгә генә әйтәм... Россия гербында да бозау рәсеме торса, дөресрәк кебек тоела миңа. Без дә бит нәкъ шул бозау шикелле. Нәрсә күрәбез, шуңа ияреп китәбез. Коммунизм күрсәк – коммунизмга, демократия күрсәк – демократиягә. Сингапур системасы күрсәк – шул системага иярәбез. Безгә нәрсәнедер күрсәтергә генә кирәк... Тик берәүгә дә әйтмәгез, яме.

Сыерлары да соклангыч. И, ул сыерның акыллылыклары! Кайберләре өйгә алып кайтырга дип әллә кая яшереп куйган онына кадәр чокып чыгара торган иде. Мин аны гаепләмим. Акылын кулланырга бүтән мөмкинлек булмагач, нәрсә эшләргә тиеш инде ул? Шуннан хуҗасы «Әй, Алланың ачы каһәре суккан нәрсә!» дигән сүзнең русчасын әйтеп, моның сыртына шланга белән тондырып ала. Теге дәшми. Әкрен генә урынына барып баса. И, аның сабырлыклары. Аны фермада: «Ярый, көтүдә йөри әле, туеп кайтыр», – дип ашатмыйлар, ә көтүчеләр: «Ярый, кайткач ашар әле», – дип, көнозын туплауда яткыралар. Ә ул дәшми. Һәм савалар. Көненә өчәр тапкыр. Сөте булмаса, тиргиләр. Я иткә җибәрәләр. И, бер карасаң, малчыда да сыер язмышлары инде...

Ә атлар... Алары нәкъ кешенең үзе кебек тоела иде. Кайберләре арыган, хәрәкәтләре талгын, күзләрендә нур сүрелгән. Ә кайберләре уйнаклап тора. Утарга кайтарып япкач та, киртә аша гына сикереп чыга. Көтүче сүгенә инде, теге тылсымлы сүзен әйтеп карый: «Борыл, анаңны...» – ди. Ә тегенең исе дә китми. Борылып кына карый да, башын чайкап, үз юлына юртып китеп бара. Бернәрсә дә эшли алмыйсың. Риза түгелсең икән, бар, куып тотып кара! Берсен куып та караганнар иде. Бер нәчәлник кушкан. Авыл буйлап көне буе куып йөрделәр. Тота алмагач, теге нәчәлник: «Атып алыгыз!» – дигән. Мылтыгын да үзе чыгарып биргән. Ә безнең авылның бердәнбер оста сунарчысы, кулын юарга дип кергәч, теге мылтыкка абынып егылып, патроннарны чылаткан. Өстәвенә мылтыгы да сынган.

Ә башкалар чормадан мылтыкларын алып, аның тутыкларын тазартып, патрон таба алмый йөргән арада, теге ат кабат утарына кайтып кергән. Шулай өйрәнгән бит инде, бер дә әллә кая китми ул, күңеле булганчы болында йөри дә ялыккач кайта, аның өчен киртәләр юк. «Иткә җибәрегез!» – дигән теге нәчәлник. Ә безнең авыл ирләре аны ялгыш ат чабышына бара торган машинага төяп җибәргәннәр. «Билләһи-валлаһи, ялгыш менә! – дип акланганнар үзләре соңыннан. – Алдашсам, шушы урында җир йотсын!» Җир йотмаган. Ә теге ат чемпион булды. Киртәләрне санламаган атны, атып алмасалар, тотып чалмасалар, билгеле инде, чемпион була.

Һе-һе-һе... Әле шушыларны язып утырам. Ә ачык тәрәзәдән күрше хатынының: «Хайван!» – дип кычкырганы ишетелә. Ире салып кайткан, шуны сүгә. Мин тиргәмим. Әйбәт кеше ул. Ясалма түгел. Ихлас. Кайвакыт төшереп алуы да, бәлки, шул әйбәтлегеннәндер. Хайван булсын, әйдә... Кеше, бәлки, бераз хайванланып та алырга тиештер. Хайваннан ерак киткән адәмдә кешелеклек тә бик булмый бит инде.



«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

ЯЗМЫШ БОРЫЛМАЛАРЫ

Кайсы гына авылга, районга барсак та, язар өчен кызыклы, үзенчәлекле геройлар эзлибез. Чистай районының Дүртөйле авылына баргач, безне Гөлнәфис Мингалимова йортына алып керделәр. «Бик тырыш, тегү-чигүгә дә бик оста апа», – дип таныштырдылар аның белән.

Чыннан да, кулы тик тормый торган тырыш, үҗәт апа булып чыкты ул. Ялт иттереп, урындык япмалары, шәл-шарфлар бәйләп куя икән.

– Бик оста бәйли торган дус кызым бар иде. Гомер буе шуның осталыгына кызыктым, тик эшләгән вакытта моңа кул җитмәде, ә инде пенсиягә чыккач, үзем дә бәйли башладым. Төрле китаплардан, газеталардан карап, бер-берсезне уздыра-уздыра бәйләү бәйләдек, – дип, фотога төшерер өчен өендә булганнарын чыгарып тезеп тә куйды.

Кул эше остасы булудан бигрәк, Гөлнәфис апаның язмышы, төгәлрәге, каенанасы белән мөнәсәбәтләре кызыклы булып тоелды безгә. Ул аның турында зур хөрмәт хисе белән сөйләде.

– Тумышым белән күрше авыл кызы мин. Ирсез калгач, әни безне, алты баланы, ялгызы гына аякка бастырды. Әллә әни дә каенана-каената белән яшәгәнгә, ирем төп йортка алып кайткач, бернинди дә каршы килү, канәгатьсезлек белдерү булмады, – дип сөйли башлады ул үзенең язмышын. – Ике каенана белән ике каената өстенә, иремнең сеңелләре дә бар иде. Барысы 14 җан яшәдек. Һәм без бик матур, бик дус тордык. Килен булып төшкәндә 19 яшь кенә иде бит әле үземә.

Берничә ел шулай күмәкләшеп яшәгәч, яшь гаиләгә шушы ук авылда йорт тергезәләр. Әле өй әзер булгач та, яшьләр, өлкәннәр яныннан аерылып чыгасылары килмичә, күпмедер вакыт бергә тора. Шулай итеп, еллар уза, гаиләдә бер-бер артлы өч бала туа. Инде балалар бераз үсеп, кайсы югары уку йортында, кайсы мәктәптә укыган елларда гаиләгә авыр сынау килә. Гаилә башлыгы – этиләре инсульт кичереп, мәрхүм була.

– 20 ел гомер иткән ирем 1989 елда үлеп китте. Бик авыр булды, якын кешене югалтуны бер кеше дә җиңел кичерми торгандыр инде ул. Әле ярый юанырга балаларым булды. Бу авылда башка якын туганнарым булмагач, Дүртөйледән күченеп китү турында уйлый башладым. Каената бик тыйнак, акыллы, төпле фикерле һәм сабыр кеше иде. Ул шунда ук ризалык бирде. Тик каенанамның безне бер дә үз яныннан җибәрәсе килмәде. Йортлары бездән ерак түгел генә иде. «Гөлнәфискә аркылы төшмә, әни. Ул бит ялгыз кеше. Ялгыз тормыш итү авыр, бәлки, парын очратыр. Без дә ялгыз калдык бит, хәлен аңлыйбыз», – дип әйткән кызларына каршы каенанам: «Сезгә Алтайга кадәр китсәгез дә ярый, аны гына җибәрмим. Мин бит аның эшкә киткәнен дә, кайтканын да карап кына торам», – дип әйткән. Каенанам бик яратты үземне. Шуңа күрә: «Мин үлгәч китәрсең», – дип, авылдан җибәрмәде.

Ялгыз тормышта 3 ел яши Гөлнәфис апа. Шуннан соң Рафаэль абый белән гаилә корып җибәрә.

– Икенче тапкыр кияүгә чыгуымны әни авыр кабул итте. Никахка чакыргач, «Мин килмим», – дип елап озатты. Иптәшемнең зурайтып ясаган фотосурәте бар иде. Шуны тотып килер иде дә, миңа күрсәтеп: «Син аны ничек алыштыра алдың?» – дип елар иде мәрхүмәкәй. Һәр анага үз баласы иң кадерлесе, иң матуры инде. Ләкин язмыш бер төрле генә бармый шул. Ирем дә: «Әни-әби, улыгыз бит инде мәрхүм. Ир өстенә ир алып кайтучылар да бар әле. Гөлнәфис белән матур итеп никах укыттык, кабул итегез инде», – дип әйтә иде. Шөкер, тора-бара ияләште, кабул итте әни Рафаэльне. Алай гына да түгел, бик нык дуслашып, матур итеп аралашып яшәделәр. Икенче ирем йөз-кыяфәте белән беренче иремә охшаган иде. Балалар да каршы килмәде. Рафаэльнең алар белән дә мөнәсәбәтләре яхшы булды, – диде Гөлнәфис апа.

Кызганыч, 4 ел элек икенче иренә дә инсульт булып, урын өстенә калган. Хәзер Гөлнәфис апа аны сабый баладай тәрбияли.

– Әнине авылда «усал Маһирә» дип йөртәләр иде. Ләкин без бик әйбәт яшәдек. Ул миңа усаллыгын бер дә күрсәтмәде. Каенанам балаларны карарга бик нык булышты. Ялгыш кына да бер начар сүз әйтешмәдек. Беренче иремнең туганнары белән әле дә якын булып, йөрешеп, аралашып торабыз, – диде ул.

Гөлнәфис апа бәйләү бәйли, балалар, оныклар белән кайнаша. Моннан тыш, бакча эшләрен бик ярата икән.

– Чәчәкләргә, гөлләргә һушым китә минем. Бакчамда кәбестәне аеруча яратып үстерәм. Аны сатар өчен тозлыйм. Кеше яратып алгач, күңелем була. Яши-яши шунысына төшендем: тормышта нинди генә авырлыклар булса да, кеше булып калырга һәм сабыр итә белергә кирәк. Сабыр төбе – сары алтын, дип юкка гына әйтмәгән өлкәннәр.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЗИФА БУЙЛЫ 82 ЯШЬЛЕК ИФИРА САЙБАТАЛОВА:

«ТУЙГАНЧЫ АШАМАГЫЗ»

Биектау районының Торнаяз авылында яшәүче Ифира апа Сайбаталова 82 яшьтә дә матурлык һәм сәламәтлек хакында онытмый. Һәр иртәсе аның: «Исән-сау уянуым өчен рәхмәт», – дигән сүздән башлана. Менә шулай дип әйткән чакта көне дә уңышлы үтә икән. Матурлык эталоны булган Ифира апа безгә дә гүзәллек серләрен чиште.

– Мин йокыдан иртәнге сәгать биштә уянам. Иң әүвәл 30 минут физик күнегүләр ясыйм. Башта караватта яткан килеш, аннан махсус җиһазларда. Гантельләр дә күтәрәм. Санкт-Петербургта, Финляндиядә яшәгәндә үк шулай күнектем. Кыскасы, гомер буе дисәң дә була. Мартта миңа 83 яшь тула. Унбер ел элек Торнаязга күченеп кайттык. Монда да гел хәрәкәтләнергә тырышам. Кышын көн саен кар көрим. Аллага шөкер, кар явып тора. Җәй көне бакчада розалар үстерәм. Торнаязда кибет юк, шуңа күрә биш чакрым ераклыктагы күрше авылга кирәк-яракка йөрим. Рәхәтләнеп җәяү барам, җәяү кайтам, – ди Ифира апа, хәрәкәттә – бәрәкәт икәнен аңлатып.

Физкультура ясагач, бер чынаяк җылымса су эчә. Ярты сәгатьтән соң иртәнге ашка ботка, 1–2 йомырка әзерли. Солы боткасына бер көнне – җиләк-җимеш, икенче көнне киви сала. Бигрәк тә ботка, шулпа, балык, атланмай, җиләк-җимешләргә өстенлек бирә. Ике көнгә бер мәртәбә маш (Азия ногыт борчагы) белән пешкән чөгендергә җитен мае болгатып ашый. Кичтән бер уч машны суда бүртерергә куя һәм икенче көнне шуны аз-азлап капкалый. Тагын бер үзенчәлеге: Ифира апа гомер буе чәй эчмәгән. Яшелен кунаклар килгәндә генә куллана. Аның өчен чәйне һиндыба (цикорий) белән куркума алыштыра. Кыш көне 2 литрга якын су эчә, җәй көне күбрәк. «Чәй эчмәгәч, башыгыз авыртмыймы?» – дип тә аптырап сорадык аннан. «Юк, Аллага шөкер, бер җирем дә авыртмый, – диде ул. – Матурлыкның бер генә сере бар: туйганчы ашамагыз! Алайса корсакка май җыела. Хәзер яшьләр чаманы белми. Сөлек кан эчә дә егылып китә бит. Кайберәүләр шуның кебек егылганчы ашый. Минем бервакытта да туйганчы ашаганым юк. Үземне чикләп яшәдем, – ди Ифира апа. – Мәрхүм ирем Хәйдәр дә сәламәтлегенә битараф булмады. Ярчык эләккән уң кулы бөгелмәсә дә, каратэ белән шөгыльләнде, физик күнегүләр ясады. Иҗат итүдән дә туктамады. Шулай булмаса, 95 яшькә җитәр идемени? Көнгә ким дигәндә биш мең адым атлый иде.

Чит ил кремнары да кулланмый ул. Иң яхшысы – алоэ согына кушылган эретелгән каз мае һәм бал. Җыерчыкларны бетермәсә дә, картаюны туктата, ди. Аны биткә генә түгел, муен һәм кулларга да сөртергә мөмкин.

Ялгыз яшәсә дә, уфтанып утыра торганнардан түгел Ифира апа. Хәзерге вакытта ире Хәйдәрнең тууына 100 ел тулуга багышлап, альбом әзерли, үзе яшәгән йортта музей ачу теләге белән янып яши. Хәйдәр ага иҗат иткән 3 меңнән артык портрет (шуның 300ләбе – татар шәхесләре) бар. Сүз уңаеннан, Хәйдәр ага Казахстанның Кустанай шәһәрендә, Ифира апа Ташкентта туган. Алар Ленинградта табышкан. Финляндиягә рәссам Хәйдәр Сайбаталовны Миккели шәһәре губернаторы Уки Воутилайнен чакырган. Финляндиянең Президентлары һәм аларның гаиләсенең портретларын ясауны да аңа ышанып тапшырганнар. Сурәтләрен ясатырга теләүчеләр чиратка языла торган булган. Ифира апа – тәрҗемәче, рәсемнәр дә ясаган. Инглиз, фин телләрен бик җиңел өйрәнгән. Менә шундый зыялы ханым ул.

Хәйдәр абый гомер буе татар авылында яшәргә хыялланган. Шуңа күрә Торнаязга күченеп кайтканнар да инде. Авылны сайлаулары да бик кызык килеп чыккан. Исеме һәм табигате тарткан. Кечкенә чакта Ифираны «торна» дип йөрткәннәр икән. Үзе дә торналар ярата, күрәсең. Капкаларына да, хәтта иренең кабер ташына да торна рәсемен ясатканнар. Ифира апаның иң зур теләге – иренең исемен, хезмәтен мәңгеләштереп, авылда музей ачып, кечкенә татар авылын саклап калу.

Сәрия МИФТАХОВА

Милли көрәш

Гадел һәм матур итеп

Татар көрәшенә игътибар булсын өчен, егетләр үзләре дә тырышырга тиеш. Алардан хәрәмләшмичә бил алышу көтәләр. Татарстанның кышкы батыры ачыкланачак «Манзара» турниры алдыннан оештыручыларның төп сүзе шул булды. Спорт һәм музыка премиясе тантанасы 14 гыйнварда Казанның «Ак барс» көрәш сараенда узачак. Хәтта җиңелгән егетләр дә буш кул белән кайтып китмәячәк.

Көрәш һәм җырны берләштергән әлеге турнир заманында «Пирамида» сәхнәсендә дә, Цирк мәйданында да узды. Хәзер исә «Ак барс» көрәш сараенда сыену урыны тапты. Димәк, теләсәң дә, теләмәсәң дә, спорт ягы өстен чыга дигән сүз. Шуңа күрә «Манзара» премиясендә төп игътибар көрәш өлешенә бирелә икән, бер дә гаҗәп түгел. Дөрес, ел саен диярлек көрәш һәм җыр-моң сөйгән тамашачының күңелен күрергә Салават килә иде. Быел Зәйнәп Фәрхетдинованы чакырганнар. Калган җырчылар исә алар микрофон тоткан арада көрәшчеләргә бераз хәл алырга мөмкинлек бирәчәк.

Бәйгедә чыгыш ясаячак көрәшчеләрне район Сабан туйларында батыр калган һәм төп турнирларда җиңү яулаган егетләр арасыннан сайлап алганнар. Быелгы ярышка Радик Сәлахов, Раил Нургалиев, Булат Мусин, Рәнис Гыйләҗетдинов, Рәдис Сәмигуллин, Ренат Дәүләтшин, Илдар Шабаев, Алмаз Галиуллин, Руслан Рәфыйков, Дилүс Закиров, Руслан Газизуллин, Илдар Хәмитов, Ришат Гайнетдинов, Динар Гатиятов, Фирдус Зәйнуллин, Альберт Ситдыйков, Рөстәм Бәдретдинов чакырылган. Турнирда 16 егетнең чыгыш ясыйсын исәпкә алсак, берсенә тамашачы арасына кереп утырырга туры киләчәк. Барысы да килеп җитә алса, әлбәттә. Әнә бит Муса Галләмов авырып киткән һәм быел келәмгә чыга алмаячак икән. Кыскасы, төп катнашучылар көнендә генә билгеле булачак.

Аның каравы җиңүчеләргә бүләкләр билгеле. Баш батыр «Манзара» билбавы һәм 100 мең сум күләмендә акчага ия булачак. Сүз уңаеннан, узган елгы турнирда Зәйдән Әлмәт аша Лаешка барып җиткән Радик Сәлахов өстен чыккан иде. Икенче урын алучыны – 75 мең сум, өченчене – 50 мең сум, дүртенче урын иясен 25 мең сум акча көтә. Җиңелүчеләр дә буш кул белән кайтып китми. Беренче әйләнештә төшеп калучылар – 10 мең, аннан соң оттыручылар 20 мең сум акча алачак. Әле бу гына да түгел. Иганәчеләр ярдәме белән узасы махсус очрашуда Теләчедән Лаешка күчкән Ранис Галимуллин белән Балык Бистәсендә үсеп, Казанда яшәүче Илмир Төхфәтуллин бил алышачак. Икесе дә – көчле егетләр, әмма авырлыклары туры килмәү сәбәпле, моңа кадәр бер мәртәбә дә көч сынаша алмаганнар. Быелгы «Манзара» аларның хыялын тормышка ашырып, матди якны яхшырту мөмкинлеге бирәчәк.

Дөрес, оештыручылар акча ягына артык игътибар бирмәскә киңәш итә. «Манзара» премиясенең генераль директоры Айдар Шәймәрданов әлеге турнир аша татар көрәшенә яңа сулыш, заманча алымнар өстәү турында хыяллана. «Бирдә җиңү – көрәшчеләр өчен дәрәҗә, мәртәбә, үзеңне күрсәтү мөмкинлеге», – ди Татарстан спорт министрының беренче урынбасары, татарча көрәш буенча атказанган спорт остасы Хәлил Шәйхетдинов. Шулай да егетләрне кисәтеп куясы итте. «Көрәшмәгән кешене «Ак барс» көрәш сараеннан арт ягына тибә-тибә мөмкин булганча еракка куачакбыз. Чакырганда ук әйттек: алыш-биреш ясыйсы булсагыз, килеп тә йөрмәгез. Безнең чын көрәш карыйсы килә. Бу – нибары 1,5–2 сәгатьлек тамаша. Монда кискен, мавыктыргыч очрашулар кирәк. Татар көрәшенә игътибар булсын дисәләр, егетләр үзләре дә матур, гадел көрәш күрсәтергә тиеш. Күпләр моны аңлый. Аңлап җиткермәгәннәрен тагын бер кисәтәбез», – диде ул.

Акча димәктән, әлеге турнирда лотерея уйнатып, җиңүчегә машина биргән вакытлар да булды. Быел исә билет сатудан кергән акчаны махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә ярдәмгә сарыф итәчәкләр. Монысы да хәрәмләшү теләген киметәчәк.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5302 данә
Гомуми тираж – 17064 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 203

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрриренең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+